| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.12.2020 ел Баулы шәһәре №244

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 114 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Баулы муниципаль районында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасына үзгәреш кертү турында

2019-nCoV тарафыннан барлыкка китерелгән яңа коронавирус инфекциясе керүне һәм таратуны булдырмау буенча кичектергесез чаралар күрүгә бәйле рәвештә Баулы муниципаль районында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 маендагы 114 номерлы карары белән расланган «2020-2024 елларга Баулы муниципаль районында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2020-2024 елларга Баулы муниципаль районында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасы чаралары» IX бүлегендә «Массакүләм физик культураны үстерү чараларын» VI бүлекчәсен әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 23 декабрендәге
244 номерлы карарына
кушымта

| «VI. . Массакүләм физик культураны үстерү чаралары | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. | Төрле яшьтәге халык катнашында яшәү урыны буенча, эшләүче, хезмәткәрләр һәм яшьләр арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрү (спорт ярышлары, спорт эстафеталары): | 2020-2024 | | | | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.1.1. | Халыкның бөтен категорияләре өчен, “ГТО” комплексын үтәп, «Лыжня России - 2020» массакүләм чаңгы ярышы | февраль 2020 | 4,400 | | 4,400 | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.1.2. | Баулы муниципаль районы предприятие һәм оешмалары профсоюзлары әгъзалары арасында ТАССРның 100 еллыгына, Баулы муниципаль районының 90 еллыгына, «Физкультурачы көне» бөтенроссия бәйрәменә багышланган, ВФСК ГТО «Үзеңне ГТОда сынап кара» массакүләм физкультура-спорт чарасы | август 2020 | 3,300 | | 3,300 | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.1.3. | Баулы муниципаль районының көрәш буенча беренчелеге | декабрь 2020 | 4,400 | | 4,400 | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1.4. | Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар арасында (16-17 яшь, 10-11 сыйныфлар) ТАССРның 100 еллыгына, Баулы муниципаль районының 90 еллыгына, Шәһәр көненә багышланган ВФСК «ГТО» «Әзер бул!» массакүләм физкультура-спорт чарасы | август 2020 | 1,100 | | 1,100 | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.1.5. | Татарстан АССРның 100 еллыгына, Баулы муниципаль районының 90 еллыгына, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгы багышланган «Көзге кросс - 2020» | сентябрь 2020 | 4,400 | | 4,400 | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.2. | Яшәү урыны буенча физкультура-спорт юнәлешендәге клуб берләшмәләрен ачу | 2020-2024 | - | - | - | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |
| 6.3. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүнең һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү буенча социаль чараларны гамәлгә ашыру | 2020-2024 | - | - | - | БМР башкарма комитеты, «ТР БМР спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» МКУ |

Баулы муниципаль районы Башкарма
комитетының эшләр белән идарә итүчесе Х.С. Мөгыйнов